**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**
**от 26.07.2022** | **№740**

## 16:16:090104:322 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, гражданнарның мөрәҗәгате нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге 16:16:090104:322 кадастр номерлы 3 987 квадрат метр мәйданлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен «йөк һәм җиңел автомобильләргә ягулык салу станцияләре» төреннән «азык-төлек продуктларын (ит, сөт, кондитер, яшелчә, җиләк-җимеш, эчемлекләр һ.б.), дару, сәнәгать һәм хуҗалык товарларын саклау складлары» төренә үзгәртергә.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 17 июнендәге 603 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы А.М. Хөснетдиновка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Хисамутдинов